КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 2 июнь г.Казань № 680

«2021 - 2024 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 ел, 13 февраль, 77 нче карары белән расланган 2021 - 2024 елларда өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын булдыру кысаларында «Сиделка» хезмәте күрсәтү пилот проектын гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 – 2024 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 ел, 13 февраль, 77 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 24 декабрь, 1278 нче; 2022 ел, 25 июль, 716 нчы, 2022 ел, 30 ноябрь, 1270 нче, 2023 ел, 21 март, 305 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган 2021 - 2024 елларда өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын булдыру кысаларында «Сиделка» хезмәте күрсәтү пилот проектын гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктның икенче абзацында «Россия Федерациясенең аерым субъектларында 2022 елда Өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидларны озак вакытлы тәрбияләү системасының типик моделен гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 29 декабрендәге 929 номерлы» сүзләрен «Россия Федерациясенең аерым субъектларында 2023 елда Өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидларны озак

вакытлы тәрбияләү системасының типик моделен гамәлгә ашыру турында» 2022 елның 15 декабрендәге 781 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктның беренче, икенче абзацларында «тәрбияләү» сүзен «социаль хезмәт күрсәтүдә, шул исәптән тәрбия буенча социаль хезмәт күрсәтүләрдә,» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Өлкән яшьтәге граждан (инвалид) (аның законлы вәкиле яисә башка ышанычлы заты) гаризада «Сиделка» хезмәтенә мохтаҗлык күрсәтелгән очракта, «Сиделка» хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ өлкән яшьтәге граждан (инвалид) турында мәгълүмат кергән көнне социаль яклауның территориаль органы өлкән яшьтәге гражданның (инвалидның) тормыш эшчәнлеге шартларын тикшерү һәм өлкән яшьтәге гражданның (инвалидның) социаль хезмәт күрсәтүдә, шул исәптән карау буенча социаль хезмәт күрсәтүләрдә индивидуаль ихтыяҗын билгеләү өчен координация үзәгенә мәгълүматны тапшыра.»;

4.2 пунктта «тәрбияләү» сүзен «социаль хезмәт күрсәтүдә, шул исәптән тәрбия буенча социаль хезмәт күрсәтүләрдә,» сүзләренә алмаштырырга;

4.3 пунктының беренче абзацында «социаль хезмәт күрсәтүдә» сүзләреннән соң «, шул исәптән тәрбияләү буенча социаль хезмәт күрсәтүләрдә,» сүзләрен өстәргә;

4.4 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) өлкән яшьтәге гражданның (инвалидның) социаль хезмәт күрсәтүдә индивидуаль ихтыяҗын билгеләү нәтиҗәләре буенча өлкән яшьтәге гражданга (инвалидка) социаль хезмәт күрсәтүдә, шул исәптән тәрбияләү буенча социаль хезмәт күрсәтүләрдә, тәрбиягә мохтаҗлыкның беренче, икенче дәрәҗәсендәге мохтаҗлыгын яисә тәрбиягә мохтаҗлыкның юклыгын билгеләү;»;

7.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Сиделка» хезмәтләре кысаларында күрсәтелә торган социаль хезмәтләрнең вакытының максималь нормалары Министрлык тарафыннан раслана.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин